# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлегенең Ләке авылы торак пунктында
2021 елда үзара салым кертү турында

**2020 елның 14 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Ләке авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Ләке авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидларыннан, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:
- Ләке авылы чишмәсен төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу һәм төзелеш эшләре өчен түләү.
- Ләке авылында янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру.
- Ләке авылы зират өчен сугу чүкече һәм генератор сатып алу;
- Ләке авылында җирле әһәмияттәге юлларны кышкы чорда кардан чистарту.
- Ләке торк пунткының урамнарын яктырту буенча өстәмә нокталар урнаштыру;
- МТЗ-82 тракторын карап тору (махсус техника өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу);
- Ләке авылы территориясен һәм юл буйларын чабу.
- Ләке авыл җирлегендә өлкәннәр һәм инвалидлар көне үткәрү өчен бүләк пакетлары алу.

3. Әлеге карарны Ләке авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Л.И.Шәрипова